**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ  КАРАР

____________  № _________

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш муниципаль районында, 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә, 2021 нче елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6424,98 сум итеп билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2020 елның 30 гыйнварындагы ПР-13 номерлы карарын 2021 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://aktanysh.tatarstan.ru/

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Җитәкче  И.И.Габдулхаев

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына 1 нче кушымта
«___» ________ ___ ел, ПР -___

2021 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе-( сум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 100 |
| 2. Кәфенләү | 300 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 1500 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден зиратка илтү | 850 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 3674,98 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |